**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**КРЫНДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЫРЫНДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.01.2020 с. Крынды № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2016 елның 19 сентябрендәге 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип тану хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы нигезендә, муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кырынды авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампаларны җыюны оештыру тәртибе турында» 2016 елның 19 сентябрендәге 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында http://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкчесе И. И. Закиров